# *МИЛЛӘТНЕҢ КӨЧЕ— ГЫЙЛЕМДӘ*

«Сукыр булмаган халык аксак кулына кермәс», дигән борынгы бабайларыбыз. Үлчәп, уйлап карыйсың да: «Безнең халкыбыз да сукыр булып яшәмәгән, үзен дә, телен дә саклый белгән, дип шөкер итәсең. 440 ел буе телеңнән генә түгел, динеңнән дә мәхрүм итү өчен кара көчләр күпме генә җан-фәрман килсәләр дә — без исән! Димәк, бил бөксәк тә, тез чүкмәгәнбез, кырсалар, үтерсәләр—үрчегәнбез, кыерсытсалар— бер-беребезгә сыена белгәнбез, үзебезне хезмәт һәм иҗтиһат белән яшәтеп, саклап килгәнбез. Хәзер инде мөмкинлегебез тагын да зуррак: киеренке көрәшләрдә яуланган, халкыбыз ихтыяры белән игълан ителгән бәйсезлегебез, мөстәкыйльлегебез бар! Яшерен-батырын түгел, күңелләребездә шик-шөбһәләр, уйланулар да җитәрлек: киләчәктә ныгырбызмы, кабат-кабат тарих тәгәрмәче астында калмабызмы, үсү, яшәү өчен нинди юллар хәерле?

Бихисап уйларым, зиһендә йөргән сорауларым белән мин академик һәм «Ватан» җәмгыяте Президенты Мирза әфәнде МӘ-ХМҮТОВКА юнәлдем. Нәрсә сөйләштек, нинди фикерләргә кагылдык?— барысы да шушында...

**Фәнзаман БАТТАЛ,**
*язучы, публицист*

**Ф. Б.—** ***Без, Мирза әфәнде, бу әңгәмәгә бик тә «кайнар» көндә утырдык. Референдум узганга да ике атна гына утте. Инде килеп, кабат берничә минуттан Россия Югары Советының, алтынны съезды баъиланырга тора. Мондый чакта курәзәче булу теләге дә туып куя. Тарихның, кай якка тәгәрәячәген абайлау бик кыен бит... Шулай да белә с е^, алдан курәсе килә! Бу әңгәмәбез журналда чыкканчы, дөнья кургәнче Татарстанда ниндирәк яңалыклар булыр дип уйлыйсыз? Куцелне тыеп тора алмыйсын,; ул яхшыга да өметләнә, иликләнеп-гиөбһәләнеп тә куй г алый. Чөнки империя, таралудан куркып, урсәләнә, тотрыклылык саклый алмый.***

**М. М.—** Алдагы тормыш турында, минемчә, хәзер берәү дә төгәл фикер әйтә алмастыр. Бик атаклы экономистлар да, сәясәт кешеләре дә аптырашта хәзер. Чөнки үзгәреп тора дөньябыз. Менә хәзер иртәнге сәгать ун. Әйе, 6 апрель... Инде әлеге съезд башлангандыр да: Анда каралырга тиешле өч мәсьәлә бар диделәр: беренчесе — хөкүмәт язмышы, икенчесе — Конституция, өченчесе — Россия Президентының вәкаләтен киңәйтү яки кысу мәсьәләсе. Инде талашырга, чәкәләшергә керешкәннәрдер. Аларның үз кайгысы кайгы бу съездда. Татарстанга, безнеке сыман республикаларга эләксә дә таякның бер очы гына эләгер.

**Ф. Б.—*Арсланнар сугышканда төлкеләр, куяннар ял итә дисезме?***

**М. М.—**Әйе. Мәскәү күбрәк үз өстенә төшкән проблемалар белән мәж килә. Нинди генә гаугалар, тарткалашлар булса да, бу съездда көтелмәгән үк хәлләр тумас, хөкүмәт калыр, чагыштырмача тыныч үтәр. Ләкин ул тыныч үтүдән генә Россиянең икътисади ягы рәтләнсә икән! Яшереп булмый, икътисад упкынга тәгәри. Гади халыкка сәясәттән бигрәк ризык кирәк, көнкүреш товарлары кирәк. Ул нишләр? Җәйне әле, бәлкем, әйбәт кенә үткәрербез. Ә көз көне кискенрәк, көтелмәгәнрәк хәлләр тууы ихтимал. •

**Ф. Б.—** ***Менә шул «ихтимал» куркыта да. Мин, мәсәлән, Татарстан буйлап куп йөрим, республиканың, авыл хуҗалыгыннан һәрвакыт хәбәрдар. Бездә икмәге дә, ите-сөте дә булыр, ач нишәу көненә калмабыз. Тик менә Россиядәге хәл шикле: чәчулек-ләре дистәләрчә еллар буе тәрбиясез ятты, крестьяннары*** **юк** ***санында. Анда кытлык башланса, ак эт бәласе***

***кара эткә, дигәндәй, авырлыкның зурысы, көнчелекнең зәһәре безгә юнәлер кебек» Әле шунысы да бар бит: безнең халык аз, каршы тору көче чамалы. Татарстанның биләмәсе дә, ялгышмасам, Россиянекеннән 250 мәртәбә бәләкәйрәк.***

**М. М.**— Ләкин хәзер биләмәнең зурлыгы-бәләкәйлеге белән, халыкның күплеге-азлыгы белән мөнәсәбәтләрне хәл итү искерде. Дөнья хәзер ј башкачарак бара. Дөньяда бит әле халкы йөз мең генә дәүләтләр бар.. Кечерәкләре дә шактый, һәркайсы мөстәкыйль. Берләшкән Милләтләр] Оешмасында һәркайсының вәкилләре утыра.

**Ф. Б.— *Үзләрен басып алырга кыжрап торучылар да юк...***

**М. М.**—Юк, юк! һәм була да алмый. Чөнки дөньяга тәүфикъ урнашып барган шикелле хәзер. Сафлану бара. Әмма аң булу да кирәк: империалистлар киләчәктә дә империализмча яшәүне куәтләр әле, үз якларына каерырлар, үз файдаларына тәртип урнаштырырга тырышырлар. Әнә күрдек бит инде, утызлап ил Гыйракны тар-мар иттеләр. Кувәйттән кысрыклап чыгарасы урында, Багдадны бомбага тотып, хатын-кызны, бала-чаганы кырдылар. Нәрсә генә димә, дөньяда әле көч хөкем сөрә. Ләкин акыл һәм гаделлек тә үз «урынын» киңәйтә. Минемчә, теге яки бу мөстәкыйль дәүләтне басып алу хурлык белән тамгалана башлаячак, оят гамәл булып саналачак. Шулай булгач, диверсияләр, провокацияләр кимер шикелле, һәрхәлдә дөньяның! сәламәт акыллы көчләре явыз көчләргә юл куймас дип беләм.

**Ф. Б.— *Референдумны кабат искә төшереп утик әле. Анъщ\ нәтижәләре безнең Татарстанның суверенлыгын дөнья куләме- ] ндә танылуга китерергә тиештер инде. Чынлыкта танулар ] булырга тиеш, дип өметләнәм.***

**М. М.**— Шушы көннәрдә Америкадан килгән өч кенә кешелек төркем | йөри 'Казанда: Илдар Агиш һәм тагын икәү... Алар белән без Югары Совет ! Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинга кереп чыктык. Шунда сөйләшеп утырганда [1] Татарстанны рәсми рәвештә тану булырмы-булмасмы дигән темага да : кагылдык. Рәсми рәвештә тану булмастыр да, дигән нәтиҗә ясарга туры килде. Сәбәбе — Россия белән ике арада каршылык теләүчеләр бик табылмас. Чөнки бу илнең кулында: атом бомбасы бар, ракеталар бар. Картада күренер-күренмәс, дөньяда сизелер-сизелмәс Татарстан хакына Америка да, Франция дә, Германия дә Россия белән низагка кермәс. Шуңа күрә башка юллары хакында уйланырга кирәк. Ягъни, үзебезнең барлыкны

сәләтләребез, гамәлләребез белән исбатлау зарур. Кабатлап әйтәм, җир шарындагы 95 процент халык Татарстанны да белми, татар халкы турында да дөрес мәгълүмат белән яшәми. Алтмышынчы-җитмешенче елларда Парижда булганда (ЮНЕСКОда бер комиссиянең вәкиле идем): «Менә мин татар, без—татарлар»... кебегрәк сүз ычкындырсаң: «Ә-ә, татарлар!.. Теге... атка атланып, камчы селтәп, сызгырып йөрүчеләрмени?» дип гаҗәпләнәләр иде. «Сезнең бабаларыгыз атка, сыерга атланып йөргән заманда безнекеләр дә шулай йөргәннәр. Ләкин без дә хәзер Европача яшибез, безнең дә культурабыз, әдәбиятыбыз бар», дип аңлата башласам, хәйран кала иделәр. Бу бит әле ЮНЕСКО бүлмәләрендә! Ә инде түбәнрәк төшсәң, гади халык арасында сөйләшсәң, анда татарны белүче юк. Россия чыгарган тарих китаплары аша гына хәбәрдар булган халыклар татарларны кыргый кабилә яки басмачлар дип беләләр. Үзебездә дә ныгый башлаган иде инде бу фикер. Башлангыч сыйныфлардан ук мәктәпләрдә: «Чыңгыз хан килгән, Бату хан килгән, өч йөз ел безне изеп яшәгәннәр, татарлар — шуларның монда калган вәкилләре», дип аңлаттылар, лабаса!

**Ф. Б.— *Унбишләп ел элек «Танки идут ромбом» дигән бер әсәр укыган идем. Анда бер майор фашистларга каршы штыклы-пычаклы сугышта дошманнарны «татар» дип куз алдына китереп сугыша. Рәхимсезрәк, усалрак булу өчен...***

**М. М.**— Нәкъ шулай! Әле хәзер дә татарны фашисттан да яманрак дип санаучы урыслар күп. Бу исә күп еллар буена ялган тарих укытуның «җимеше». Менә шуңа күрә дөньяның безне таный башлавы бик шикле.

**Ф. Б.— *Сез мине сөендермәдегез әле бу сузләрегез белән, Мирза әфәнде. Куцелнец җилкенеп торган өмет канатлары бар иде...***

**М. М.**— Ләкин канатларны салындыру ярамас. Халык дипломатиясе дигән нәрсә бар дөньяда. Әле шушы арада «Ватан» җәмгыятенең җыелышы булды. Әлеге америкалыларны да чакырган идек. Хәзер безгә үзебезне халык дипломатиясе юлы белән таныта башларга вакыт. Ул ни дигән сүз? «Без — татарлар, безнең борын-борыннан ук дәүләтчелегебез булган, шун-дый-шундый тарихыбыз, гамәлебез, танылган шәхесләребез бар», ди-ди сөйләргә, аңлатырга, язарга тиешбез. Ә моның өчен нигезебез бар. Зыялы һәм мәшһүр шәхесләребез дә җитәрлек. Америкага киткән галим академик Сәгъдиев белән генә чикләнми бездә

талантлар. Менә Франциядә бик атаклы вулканолог бар. Ничек әле фамилиясе, Лоуреисмы? Француз булып йөри, ләкин тамыры татардан. Әле менә һәркайсыбызга мәгълүм фактлар: өч ел элек шахмат буенча дөньяның иң яшь гроссмейстры татар иде. Мин монда Алисә Галләмованы күздә тотам. Инде менә 17 яшьлек Гата Камски-ебыз да иң яшь гроссмейстр! Икесе дә татар балалары! Сүз уңаенда искә алдым аларны, мисал өчен... Дөнья җәмәгатьчелеге фикерен туплау, ныгыту максатында милләтнең шундый атаклы кешеләренә таянырга кирәк. Чөнки атаклы затларның кемлеген һәр халык белә, шуларга карап, аларның милләтенә дә бәя бирергә өйрәнә.

**Ф. Б.— *Мисалы башка милләтләрдә дә куренеп тора. Даг-спган халкын, мәсәлән, Рәсул Гамзатов кутәрде, дөнья каршында танытты.***

**М. М.**— Шулай шул, шулай!.. Бик дөрес! Ягъни: «Кем син? Дагстанлымы? Беләм, беләм: син Рәсүл Гамзатов халкыннан буласың!..» Менә безгә дә тарихыбыздан гына түгел, бүгенге тормышыбыздан да кабилиятле кешеләребезне табып торырга кирәк. Табу өчен, әлбәттә, үстерә белү бик мөһим. Фуат Мансуров, мәсәлән, Большой Театрда дирижер. Аны беләләр! Инде сәләтләребез, гамәлләребез белән исбатлау зарур. Кабатлап әйтәм, җир шарындагы 95 процент халык Татарстанны да белми, татар халкы турында да дөрес мәгълүмат белән яшәми. Алтмышынчы-җитмешенче елларда Парижда булганда (ЮНЕСКОда бер комиссиянең вәкиле идем): «Менә мин татар, без—татарлар»... кебегрәк сүз ычкындырсаң: «Ә-ә, татарлар!.. Теге... атка атланып, камчы селтәп, сызгырып йөрүчеләрмени?» дип гаҗәпләнәләр иде. «Сезнең бабаларыгыз атка, сыерга атланып йөргән заманда безнекеләр дә шулай йөргәннәр. Ләкин без дә хәзер Европача яшибез, безнең дә культурабыз, әдәбиятыбыз бар», дип аңлата башласам, хәйран кала иделәр. Бу бит әле ЮНЕСКО бүлмәләрендә! Ә инде түбәнрәк төшсәң, гади халык арасында сөйләшсәң, анда татарны белүче юк. Россия чыгарган тарих китаплары аша гына хәбәрдар булган халыклар татарларны кыргый кабилә яки басмачлар дип беләләр. Үзебездә дә ныгый башлаган иде инде бу фикер. Башлангыч сыйныфлардан ук мәктәпләрдә: «Чыңгыз хан килгән, Бату хан килгән, өч йөз ел безне изеп яшәгәннәр, татарлар — гнуларның монда калган вәкилләре», дип аңлаттылар, лабаса!

**Ф. Б.— *Унбишләп ел элек «Танки идут ромбом» дигән бер әсәр укыган идем. Анда бер майор фашистларга каршы штыклы-пычаклы сугышта***

***дошманнарны «татар» дип куз алдына китереп сугыша. Рәхимсезрәк, усалрак булу өчен...***

**М. М.**— Нәкъ шулай! Әле хәзер дә татарны фашисттан да яманрак дип санаучы урыслар күп. Бу исә күп еллар буена ялган тарих укытуның «җимеше». Менә шуңа күрә дөньяның безне таный башлавы бик шикле.

**Ф. Б.— *Сез мине сөендермәдегез әле бу сузләрегез белән, Мирза әфәнде. Кунелнен җилкенеп торган өмет канатлары бар иде...***

**М. М.—**-Ләкин канатларны салындыру ярамас. Халык дипломатиясе дигән нәрсә бар дөньяда. Әле шушы арада «Ватан» җәмгыятенең җыелышы булды. Әлеге американлыларны да чакырган идек. Хәзер безгә үзебезне халык дипломатиясе юлы белән таныта башларга вакыт. Ул ни дигән сүз? «Без—татарлар, безнең борын-борыннан ук дәүләтчелегебез булган, шун-дый-шундый тарихыбыз, гамәлебез, танылган шәхесләребез бар», ди-ди сөйләргә, аңлатырга, язарга тиешбез. Ә моның өчен нигезебез бар. Зыялы һәм мәшһүр шәхесләребез дә җитәрлек. Америкага киткән галим академик Сәгъдиев белән генә чикләнми бездә талантлар. -Менә Франциядә бик атаклы вулканолог бар. Ничек әле фамилиясе, Лоуренсмы? Француз булып йөри, ләкин тамыры татардан. Әле менә һәркайсыбызга мәгълүм фактлар: өч ел элек шахмат буенча дөньяның иң яшь гроссмейстры татар иде. Мин монда Алисә Галләмованы күздә тотам. Инде менә 17 яшьлек Гата Камски-ебыз да иң яшь гроссмейстр! Икесе дә татар балалары! Сүз уңаенда искә алдым аларны, мисал өчен... Дөнья җәмәгатьчелеге фикерен туплау, ныгыту максатында милләтнең шундый атаклы кешеләренә таянырга кирәк. Чөнки атаклы затларның кемлеген һәр халык белә, шуларга карап, аларның милләтенә дә бәя бирергә өйрәнә.

**Ф. Б.— *Мисалы башка милләтләрдә дә куренеп тора. Даг-стан халкын, мәсәлән, Рәсул Гамзатов кутәрде, дөнья каршында танытты.***

**М. М.—**Шулай шул, шулай!.. Бик дөрес! Ягъни: «Кем син? Дагстанлымы? Беләм, беләм: син Рәсүл Гамзатов халкыннан буласың!..» Менә безгә дә тарихыбыздан гына түгел, бүгенге тормышыбыздан да кабилиятле кешеләребезне табып торырга кирәк. Табу өчен, әлбәттә, үстерә белү бик мөһим. Фуат Мансуров, мәсәлән, Большой Театрда дирижер. Аны беләләр! Инде тагын... Рудольф Нуриев заманында «теге якка» качып китәргә мәҗбүр булды. Балет биюләрен кую буенча иң зур оста икән. Аны Франция чакыра, Италия чакыра... Бөтен дөнья белә! Ул да

татар баласы. Менә Ирек Мөхәммәтов китте хәзер. Лондонда калды. Ул да атаклы!.. Татарстанны, татар халкын әнә шундый шәхесләр күбрәк булган саен ныграк таныячаклар.

Ләкин халык дипломатиясе атаклыларны санап утырудан гына гыйбарәт түгел. Уйларга, төпле программалар булдырырга кирәк: нәрсә мөһимрәк, кемнән башларга, ничек дәвам итәргә? Мәсәлән, «Ватан» җәмгыяте чит илдә яшәүче татарларны эзли, таба, дөньяга таныта, алар белән элемтәдә тора. Монда да, чит илләрдә йөргән вакытта да үзара ярдәмләшеп яшәү турында сөйләшүләр алып барабыз. Ләкин алар очраклы түгел, бәлки даими булырга тиеш. «Ватан»ның гына аралашуы белән канәгатьләнмичә, бөтен халкыбызны аралаштырырга кирәк.

**Ф. Б.— *Татар җамлы татарларны!***

**М. М.**— Татар җанлы булу бер хәл. Ә менә татарлыкны куәтләү өчен файдалы эшләр кылу—мөһимрәк нәрсә. Горурлыгын күрергә телисең икән, мәшәкать һәм авырлыкларын күтәрә белү дә зарур. Бердәмлекне көчәйтүдән башка танылуга ирешү авыр нәрсә.

**Ф. Б.— *«Бердәмлек» дигәннән, иҗтимагый хәрәкәтләр дә икегә аерылып китә кайчак. Әле күптән түгел, февраль башында, ТИҮ җитәкчелеге белән Милли Мәҗлес башлыклары арасына да «кара мәче» керде. Шушы җәһәттән сорау: иҗтимагый оешмаларның, кайсы мөһимрәк? Бездә әле «Иттифак» фиркасе дә бар...***

**М. М.**— Менә монысы авыр сорау. Аңа төп-төгәл итеп, кистереп җавап бирүне беркем дә үз өстенә алмастыр... Татар иҗтимагый үзәге үзенең эшен эшли, татар дөньясын азатлык өчен, мөстәкыйльлек **өчен** көрәшергә кирәк дигән фикергә халыкны җәлеп итә. Инде яхшы беләбез: татарның җитмеш проценттан артыгы **Татарстаннан** читтә. (Әмма бу алар чит илләрдә дигән сүз түгел. Россиядә, мәсәлән, алар тарихи ватаннарында яшиләр. Мин бу хакта язып та чыктым.) ТИҮ бинилһая зур эш алып бара. Инде «Иттифак»ка килсәк, урыслар белән сөйләшүләр искә төшә. Алар: «Сезнең Бәйрәмова экстремист, ул безне куарга лозунглар кычкырып йөри», диләр. Ә мин әйтәм: «Сез, җәмәгать, Бәйрәмованы гына күрәсез. Ник сез Жириновскийны онытасыз? Жириновскийның зәһәрлегенә каршы **тору** өчен йөз Бәйрәмова кирәк». Чөнки Жириновский сүздә генә түгел, басмада татар белән **башкортны** куу белән куркытмак булды. Кызу канлылар, тәртәдән чыгучылар һәр милләттә, һәр партиядә бар. Бәлки аларның уңай ягын да табу кирәктер. Алар

сискәндермәсә, бер якка чәчрәп чыгып, кискен сүз әйтмәсә. халыкның фикере «ләббәйкә!» булып кына калыр иде, мөгаен. Коткы салу начар, билгеле, хуплап бетерергә ярамый. Дәлил белән көрәшү мәслихәтрәк. Анысы дөньяга да, демократиягә дә, кешелек законнарына да сыя.

**Ф. Б.—** ***Бер сәеррәк тоелырдай сорау да биреп утәсе килә. Сез — академик, Сезне татар зур галим, акыл иясе дип таный. «Ватан» җәмгыяте Президенты икәнегезне дә белеп яшиләр. Форсат туса, Татарстан Президенты булып сайланырга телəрсезме?***

**М. М.** һай, теләмәс идем. Беренчедән, анда бик зур физик көч кирәк. Минем аңа түземем, көчем җитмәс иде. Анда көне-төне эшләргә кирәк. Әйтәләр бит: Югары Советларда утыручылар тәүлеккә 17 шәр сәгать тә эшлиләр, дип. Мин аңа ышанам. Күпме документ әзерләргә кирәк, күпме бәхәскә, гаугага чыдарга кирәк!.. Меңләгән проблемалар анда. Президентлык - яшь кешене дә хәлдән тайдыра торган вазифа. Аның өчен минем әзерлегем дә юк. Шунысына да игътибар итик: Югары Совет сессияләрендә (халыкча әйтсәк) булыр-булмас депутатлар никадәр! Үзләре дә аңламастан гауга, бәхәс куптаручылар гына да ни тора... Ә чит илләр парламентларында юридик, социаль, экономик белемнәре булган тәҗрибәле депутатларны гына сайлыйлар. Алар сафсата сатып утырмыйлар. А\ар белемгә таянып эш итәләр, белемгә таянып сүз сөйлиләр, һәр файдалы сүзне кирегә сукалап вакыт үткәрмиләр. Тәкъдимнәрне дә бик уйлап кына кертәләр. Дөрес аңлашылсын, мин үзебезнең депутатлардан көлмим, алар-ны гаепләмим дә. Чөнки сәяси яктан халкыбыз да сукыр иде диярлек. Халкы нинди — депутатлары шундый. Мисал кирәкме? Безнең районда галимгә 5 процент тавыш бирелде, ә шоферга— 15... Россия парламентында шофер файдалырак сүз әйтә аламы, әллә галимме? Мондый инану акылларга Лениннан сеңгән, һәрбер кухарка җитәкче була ала дигән сүзләренең чагылышы бит инде бу! Сүзне озайтмыйк. Президент булу турында уйламыйм да. Бигайбә!..

**Ф. Б.—** ***Куреп, сызланып яшибез: элекке «тугандаш халыклар» пычакка-пычак киләләр. Әрмәнстанда, Әзәрбайҗанда кан коеш бара, Молдавия болгана. Нинди көчләр болгатуын да бик яхшы беләбез: шовинистлар, империяне саклап калырга маташучылар. Шул бәрелешләр һәрвакыт бер сорау тудыра. Мөстәкыйль Татарстаныбызга каршы да кораллы провокацияләр оештырмаслар микән? Алай булса, безнең халык,***

***коралсыз халык арысланнарга каршы торырга ниятләгән куяннар хәлендә калачак бит.***

**М. М.-** Бу очракта дөнья җәмәгатьчелегенә мөрәҗәгать итүдән башка чарабыз юк. Мәсәлән, Берләшкән Милләтләр Оешмасына, төрле дәүләтләр җитәкчеләренә: «Карагыз әле, безне бер гаепсезгә кыйныйлар, вәхшиләрчә бетермәкче, таламакчы булалар!» дияргә, яклау омет итәргә тиеш булабыз. Үзегез дә беләсез, кораллы көчләребез юк. Булган суәттә дә хәлебез әлләни үзгәрмәячәк.

**Ф. Б.—** ***«Ватан» җәмгыятенең, дөньякуләм эш йөртуен беләбез. Бу җәһәттән «профилактик» чаралар курәме ул?***

**М. М.**— «Ватан»—әлегә бик зәгыйфь җәмгыять. Аның бюджеты да юк. Читтән килгән агай-энедән хәер-сәдака алып. шул исәпкә яши торган бәләкәй генә җәмгыять. Без хәзер аны көчәйтү, функцияләрен киңәйтү, вәкаләтен үстерү, чит илдәге милләттәшләр ярдәмендә матди хәлен дә ныгыту хакында уйланабыз. Безнең, мәсәлән, Төркиядә татарлар бар, әмма татар җәмгыяте юк әле. Чөнки берләшмәгәннәр. Кытайда һәм Германиядә дә шундый ук хәл. Ә менә Америкада бергәлек сизелеп тора. Андагы җәмгыятьнең рәисе Искәндәр Бадай дигән галим. Игътибар итегез: чын демократия, цивилизация булган җирдә берләшү бар. Безнең бурыч — дөнья буйлап сибелгән татарларыбызны табу, бердәмлеккә юл ачу. Киләчәктә төрле илләрдәге җәмгыятьләр үзара элемтәдә торып хәбәрләшеп яшәсеннәр иде дип тырышабыз. «Ватаы»ның функциясе дә нәкъ шул. Инде менә җәмгыятебезнең «Дөнья» исемле газетасын чыгара башладык. Күргәнсездер, матур да, пөхтә дә булып чыкты, эчтәлеге дә бай сыман. Татарча мәкаләләрен латин хәрефе белән җыйдык. Бераз гына инглизчә язмалары да бар. Бер өлешен — Америкага, шактыен Төркиягә җибәрдек. Аның язмышы, дөнья җәмәгатьчелегенә йогынтысы нинди булыр — хәзергә өздереп әйтү кыенрак. Максат: аны халкыбызның зур трибунасы итү. Аңа ирешү өчен бер-ике ел гына җитмәс әле.

**Ф. Б.—** ***Кайчак куңелне өметсезлек тә биләп ала, Мирза тугай. Хуш, дисең уз-узеңә, тырышабыз, кайгыртабыз, узара берләшу өчен мәшәкать чигәбез, кайнашабыз... Ләкин 5 тиенлек куян, 10 тиенлек зыян гына тугелме бу омтылышларның, гамәлләрнең нәтиҗәсе? Әйтик, Америкада, Төркиядә, Финляндиядә һәм башка төбәкләрдә яшәуче татарлар тора-бара тегеләрнең генә теленә, гореф-гадәтенә кучеп бетмәсләрме? Аларның, минемчә, безнең якка кайтулары елдан-ел шиклерәк.***

**М. М.**— Ул илләрдә төрле буын татарлары яши. Сөйләшкәндә, аралашканда шул сизелә: алар өчен Татарстан әкияттәге бер ил сыман тоела. Кайчандыр монда яшәп киткәннәре туган җирнең туфрак исенә кадәр сагыналар, ерактагы газиз моңны якынайтырга тырышкандай тоелалар. Читтә туганнары әти-әниләренең Татарстан, Россия турындагы истәлекләре белән яшиләр. Россия дип әйтүем гаҗәпләндермәсен, татарның җире хәзерге Татарстан белән генә чикләнмәвен үзегез дә беләсез. Идел буе да, Урал да, Себер ягы да татар җире булуын тарих раслап тора бит... Чит илләрдәге татарларның теләк-омтылышларын үлчәүгә салсаң, туган җир ягы ныграк тарта сыман. Монысы да бар: безгә килүчеләре тормышыбызның сүтек, таркау булуын күрәләр дә кәефләре төшә. «И, монда бездәгедән дә яманрак икән әле», дип кайтып китәләр.

**Ф. Б.— *Минем төп өметем — «СССРдагы» татарларда. Уңышлы уткән референдумыбыз, Татарстанның уз бәйсезлеге-нә баруы аларны бу якларга ныклап тарта башлар. Шушы җәйдә ук куплэп кайтырлар сыман. Бик ук ашкынып тормаганнары да кученер. Ник дисәк, белеп торабыз: һәр милләтнең уз илендә башка милләтләрдән арынасы килә, «килмешәк» милләтләрне кысрыклыйлар, юньле эш яки фатир бирмиләр, Россиянең куп төбәкләрендә «антирусское двио§сение»не тыю кочәя. Бу инде татар һәм башка милләтләрнең җәмгыятьләрен дә законсыз дип тану. Горурлыгы, милли хисе булган милләттәшләрнең куплэп кайтуын көтәм мин, Мирза әфәнде.***

**М. М.**— Юк, булмаячак андый зур хәрәкәт. Бик каты кыссалар да булмаячак! Үзбәкстанда, мәсәлән, үз милли интеллигенциясе үскәч, татарларны кыса башладылар. Мин 50 нче, 60 нчы еллар хакында сөйлим... Ләкин кайтучылар бик аз булды. Хәзер дә әлләни аерма сизелмәячәк. Күреп торабыз, лабаса: Татар иҗтимагый үзәге әһелләре татарларны шушы төбәккә туплау-җыю өчен күп тырышалар, әмма күзгә ташланырлык нәтиҗә юк әле. Алабугада завод төзелү ихтималы күренгәч, Казакъстанда, Үзбәкстанда чыга торган газеталарда мөрәҗәгатьләр, игъланнар бастырдык, кайтырга димләп... Оештыру өчен вәкилләребезне дә җибәрдек. Әмма бик әз кеше кайтты. Үзенең еллар буе көйләгән оясын, өйрәнгән эшен, мохитен ташлап, булыр-булмас квартирга, шикле хезмәт хакына, ошар-ошамас эшкә өметләнеп кайтуны хуп күрүчеләр хәзер дә күп булмастыр. Күченеп йөрү җиңел түгел бит ул! «Кайту» дигән сүз дә ачыклык сорый. Самар-Сарытауда, Әстерханда туып-үскән татарларның Татарстанны күр-

мәгәннәре дә күп. А\ар бит буыннан-буынга шунда яшәгән кешеләр. Туган җирләре дә шунда.

**Ф. Б.— *Анысын мин дә беләм. Ләкин шовинизм белән агуланган урыслар белми бит ул чынбарлыкны. Тарихның бозып укытылуын да истән чыгармасак, урыслар, һичшиксез, куа башлаячаклар. Шовинистлар «татарның туган җире—Татарстан» дип кенә беләләр.***

**М. М.** — Андыйлар — наданнар...

**Ф. Б.— *Кызганычка каршы, бу чорда наданлыкның, җгщу ихтималы зуррак. Куп очракта наданнар хәл итә бит.***

**М. М.**— Шуңа күрә хәзер пропаганда эшен көчәйтергә кирәк. Татар кем, Татарстан нәрсә? — урыслар да, чит илләрдәге башка халыклар да белсен. Бер мисал: әгәр сине чит җирдә, үзеңне белмәгән якта талый башласалар, бәлки, яклаучы да табылмас. Ә инде кемлегеңне белгән төбәктә кыйнарга, таларга керешсәләр һәм син кычкырсаң, мөгаен, күпләр ачык тәрәзәдән булса да якларга теләрләр, тавыш бирерләр. Монда да шулай: татар турында дөньяда мәгълүматны күбрәк, киңрәк таратырга кирәк. Аның үзе яшәгән җирдә хакы да, хокукы да барлыгы һәркайда, һәр милләткә мәгълүм булсын.

**Ф. Б.— *Таралып яшәгән милләткә уз телен саклау, туган телдә белем алу да кыен бит. Бигрәк тә читтә, Россиядә, башка дәүләтләрдә...***

**М. М.**— Үзебездә дә җиңел түгел. Казанда, мәсәлән. 35 нче татар мәктәбе бар иде. Заманасында без аңа акчасын бирдек, җиһазын таптык, күтәрергә тырыштык. Татар бистәсе, татар балалары... Шушы бистәдә зур-зур йортлар сала башладылар. Табигый ки, яңа квартираларны Ленин, Киров районында яшәгән урысларга да бирә башладылар. Аларга аерым мәктәп юк. Кая барырга, нишләргә? Шушы ук мәктәптә укытырга туры килә. Урыс класслары ача башлауга, татар балаларының ата-аналары киләләр дә: «Мин дә баламны урысча укытырга телим», диләр. Чөнки (ул вакытта) татар теленең перспективасы түбән. Хәзер ул мәктәп саф татар мәктәбе түгел инде'.

**Ф. Б.— *Димәк, мәктәптә дә, башка уку йортларында да татар теле имтиханнарын төп имтихан дәрәҗәсенә кутәрер-гә кирәк.***

**М. М.**— Фикерең дөрес, Фәнзаман әфәнде. Ләкин бу фикер Татарстанны гына күздә тотканда файдалы. Бу — җитмеш стимулның берсе генә бит. Ә Мәскәүдә нишләргә? Мәскәүдә дә татар укучысыннан яки студентыннан татарча имтихан алыргамы? Ике бала имтихан бирә икән, аерым комиссия утыртыргамы? Мөмкин түгеллеге күренеп тора. Нишлисең бит, Франциядә — французча, Англиядә — инглизчә, Россиядә — урысча сөйләшәләр.

**Ф. Б.— *Алай булгач, Татарстандагы халыклар да татарча сөйләшергә тиеш тугелме соң? Россиядәге татар урыс телен мәмдбури белә, ә Татарстандагы урыс ике татар уз телендә сөйләшсә дә упкәли. Гаделсезлек бит бу. Яшерен-батырын ту-гел, референдумда да урысларның шактый өлеше итәктән тартты.***

**М. М.** Урыс халкын, бигрәк тә гади урысларны гаепләргә ашыкмыйк. Бу очракта булып үткән хәлнең асылын, сәбәбен игътибарга алыйк. Референдум алдыннан Мәскәү радиосы һәм телевидениесе, газеталары Татарстан халкына шундый басым ясадылар ки, хәтта саф күңелләр дә гарипләнерлек булды. «Яңа Карабах» белән дә өркеттеләр, урысларның «икенче сортлы» булып калачагы, Татарстаннан куылачаклары белән дә куркыттылар. Ә информация берьяклы: Мәскәүне тыңлыйлар, Мәскәүне карыйлар, Мәскәүне укыйлар... Үзебездә чыга торган урыс матбугаты да,

' 35 нче мәктәптә хәзерге көндә 1 нче татар гимназиясе ачылды. Әмма ләкин балалар тәнәфес вакытында барыбер русча сөйләшәләр.

нигездә, пропаганданы Мәскәүчә алып барды — икеләндереп, шөбһәләндереп торды. Әгәр урыслар татар телен белсәләр, татар матбугатын аңлый алсалар, төп халыкның күңеле изгелектә икәнен, һичшиксез, белерләр иде. Үзебездәге урыс матбугаты чынбарлыктан тайпылмаса, урыс телле кешеләрнең башын бутамаса, нәтиҗә тагын да күңеллерәк, гаделрәк булачак иде. Кабатлап әйтәм, ике халык ике төрле информация белән яшәде. Татар галимнәре, язучылары, җитәкчеләре, журналистлары чын тарихны, чын хәлне ничек кенә дәлилләп, тирәнрәк анализлап язмасыннар татар матбугатында, аларның язганы республика халкының шактый өлешенә барып җитмәде.

**Ф. Б.— *Урыс матбугаты дигәннән, Мирза әфәнде, Литва җиренә соңгы сәфәрем искә төгиә дә тора. Литвача укый да белмим, аңламыйм да бит***

***инде... Шуңа курә аларда чыга торган газеталарның урысчаларын гына укып йөрдем- Гаҗәпләнүемнең чиге булмады: Литваның мөстәкыйльлегенә каршы бер генә җөмлә дә юк! Гади халык белән сөйләшкәндә, җитәкчеләр, галим-голәмә белән әңгәмә корганда да шушы гаҗәпләнүемне әле-дән-әле әйтә тордым. «Нәрсәсе гаҗәп аның?!—диделәр.—Суверенитет— азатлык дигән сүз. Ягъни, изге нәрсә. Азатлыкның капма-каршысы — коллык. Без бит инде коллыкны пропагандалауга юл куя алмыйбыз!». Шунысын да аңладым: анда Литва мәнфәгатьләренә каршы хәрәкәт итүче, күрше илләр (шул исәптән Россия) файдасына пропаганда алып баручы партияләр дә тыелган, һәм бу, минемчә, бик табигый: Татарстанда яшисең икән, Татарстанның тәрәкъкые өчен хезмәт ит!..***

**М. М.**— Әле беркөнне, референдумга хәтле, кердем күршемә. Җитәкче кеше, аңлы кеше. Ләкин референдумга мөнәсәбәте шулкадәр тискәре-исем китте!.. Мин аңлатырга керештем. Ягъни, теге мәсьәләнең, бу мәсьәләнең асылы нәрсәдә икәнен. Тора-бара ул аптырады: «Карале, малай, бу якларын белми идем», ди. Ниһаять, аңлады, карашы да яктырып китте, хәтта!..

**Ф. Б.**— ***Үзебездәге урыс матбугатына аптыраган инде... Гел кирегә сукалау бит. Узган ел түзмәдем, Президентның үзенә керергә булдым. Дөресен генә әйткәндә, дулкынлануымны, үртәлүемне дә сизгәндер. «Менә, Минтимер туган, матбугатны көчәйттек, яңадан-яңа урыс газеталары да ачып җибәрдек. Куанасы гына кебек. Ләкин карагыз: барысы да диярлек чынбарлыкны суялар, хәтта, үзегезнең изге ният белән әйтелгән һәр сүзегездән көләргә, кире мәгънә чыгарырга маташалар. Нә, сөенечме шул?» — дидем... Минем фикеремчә, урыс газеталарының башына да изге ниятле, намуслы, хакыйкатькә хыянәт итмәүче мөхәррирләр куярга кирәк. Инде дә Президент җавабына килсәк, болайрак диде: «Матбугат төрлесен яза инде ул. Сүз иреге бит». Ә мин аның җавабы белән һаман да килешә алмыйм. Суз иреге дигән төшенчә гаделлеккә дә хилафлык кылырга ярый дигән суз түгел.***

**М. М.**— Әлбәттә, матбугат, кайсы гына телдә чыкмасын, гадел булырга тиеш. Әле менә Сез Литва турында әйтеп үттегез. Балтыйк буе дәүләтләрендә хәл башкача шул: тормышны, тарихны аңлау да, иҗтимагый хәрәкәт тә, халыкның

фәһемләве дә... Нык аерыла! Анда гомумхалыкның культура дәрәҗәсе югарырак дисәм дә, мөгаен, ялгышмамдыр.

**Ф. Б.— *Шулай шул. Алар бит бу империя коллыгында безгә караганда ун мәртәбә кимрәк булганнар...***

**М. М.**— Сәбәбе ул гына түгел. Нәрсә генә дисәгез дә, Европа цивилизациясе тәэсирендә үскән халыклар бит алар. Шуңа күрә психологиясе дә үзенчәлекле андагы гавамның. Тагын бер факт: ул илләр социализмда да безнең кебек 74 ел яшәмәделәр, 1940 елдан гына СССРга «керделәр», ягъни унсигезенче елдан кырыгынчы елга кадәр мөстәкыйльлекнең тәмен татып калганнар иде. Без аларны монда «милләтче буржу-аз-фәлән» дип сүтеп яшәсәк тә, барыбер алар ирекле халык булып яшәделәр. Шул вакытта яшәгән, шул чакта азатлык хәрәкәтендә катнашкан шактый кешеләре хәзер дә исән! Алар азатлыктан авыз иткән шаһитлар. Истәлекләре дә, тәҗрибәләре дә җитәрлек һәм күбесе аңлату эшләре алып баралар. Бу яктан без мәхрүм. Безнең зыялы кешеләребез дә берьяклырак бит әле. Татар җанлы, милли хисле, гыйлемле шәхесләребез, нигездә, гуманитарийлар. Алар, сүз дә юк, азатлык хәрәкәтендә актив катнашалар. Табигать, техника фәне вәкилләре бу эштә күпме катнаша? Юклар алар, юклар... Юк дәрәҗәдә азлар. Шуның өстенә татарча да белмиләр. Татар тарихы, әдәбияты, мәдәнияты белән кызыксынудан ерак йөриләр. Кызыксынганнары да үз телебездә укый алмыйлар. Күрәсез, интеллигенциябезнең мөмкинлекләре чикле. Димәк, аның дөньяга карашы, фикерләү сәләте дә таррак булып тора. Милли, иҗтимагый хәрәкәтебезне бөтендөнья яссылыгында барлап карасак, үсү мөһимлеге көн кебек ачык. Әйтик, экология проблемалары. Аларны гуманитар белемгә таянып кына хәл итеп булмый, лабаса! Техник гыйлемгә, физика, химия, математика шикелле фәннәргә таяну да бик зарур. Экология проблемасы — ул промышленность проблемасы. Менә шуларны аңлаган хәлдә үзебезнең зыялыларыбызны барлап карасак, бер генә аякта басып торучыны хәтерләтәбез.

**Ф. Б.— *Димәк, бөтен карап торганыбыз гуманитарийлар...***

**М. М.**— Аларның да бер өлеше генә. Шактыеның фәһемләве коммунистик тәрбия, коммунистик сәясәт дәрәҗәсеннән узмый. Фәнни коммунизм кафедраларында алган белем белән генә ерак китеп булмавы инде аңлашылды... «Буа (Минзәлә, Бөгелмә...) районында башлангыч партия оешмасының хәрәкәте» кебегрәк темаларга диссертация яклаган галимнәрдән әлләни көтеп тә булмый.

Фәкать марксизм-ленинизмны гына өйрәнеп үскән кешеләр ич! Көрәштә бик дәртле, милли җанлы булсалар да, белем кытлыгы комачаулап тора, дөньяны танып белүләре җитми.

**Ф. Б.— *Без шактый сөйләштек, киңәштек, Мирза әфәнде. «Татарстан» журналы укучыларын кызыксындырган куп темаларны кузгатып карадык, дисәм дә ялгыш булмас. Бу әңгәмәне тулырак, файдалырак иту хакына тагын нәрсә өстәр идегез? Мөһим сузләрегез, фикерләрегез качып калмасын иде.***

**М. М.** -Милли хәрәкәтнең көчәюенә берничә ел үтте. Күп уйладык, төрле фразаларны чагыштырдык. Кирәкле дип саналган фикерләрнең дә әйтелми, язылмый калганнары юктыр инде шәт. Барысы да әйтелеп бетте, һәр милләтне алга этәргән иң зур көч — белем ул. Сез миңа табып бирегез яһүдләрдән торган колхозны. Юк, дисезме? Әйе, юк! А\ар да Совет чорында яшәде, таралып яшәде. Ләкин үз милләтләрен югалтмадылар, белем белән ныгыттылар, үстерделәр, күтәрделәр. Югыйсә бит элегрәк итек чистартучы да булган яһүд, чәч алучы да, кара эшче дә... Алар совет властенда бушлай белем алу форсатыннан бик белеп файдаландылар. Ә безнең татар элек тә Донбасс шахтасына акча сугам дип барды, хәзер дә. Инде менә безнең татарыбыз акча хакына теләсә кайда нефть чыгарып йөри. Безнең милләт бүгенге акча, бүгенге ризык хакына тырыша, ә яһүд үз милләтенең киләчәген күздә тотып иҗат итә. Бездә күп кенә ата-аналар, баласы сигез сыйныфны бетерүгә үк: «Бар әле, акча эшләп кайт, акча юк», диләр. Ә акыллы милләттә алай эшләмиләр, тирән белемне һәр нәрсәдән өстен куялар. Чөнки дөньяда интеллектуаль потенциал дигән бик мөһим төшенчә бар. Белемнең, гыйлемнең кадерен белгән милләт кенә үсә. Шуны онытмыйк!

**Ф. Б.— *Сезнен, белән сөйләшкәндә әткәмнең васыятен утәу хисе дә булды куңелдә, Мирза әфәнде. Үләр алдыннан хәер-фати-ха биргәндә: «Дөньяда гафил булып яшәмә» диде дә, авыр сулап: «Хәер, «гафил» сузен аңлаучылар юктыр инде хәзер, син дә белмисеңдер», дип куйды. Ә мин «беләм» дидем, Сезнең катнашта чыккан «Гарәпчә-татарча-русча сузлек»не курс эттем. Сөенде мәрхум: «Бетмибез икән әле, милләтне кайгыртучы кешеләр бар икән!» — диде. Болай дип тә өстәде: «Син, улым, шундый кешеләр белән аралашырга тырыш, шулар белән киңәшеп яшәу юлын тап...» һәм менә, журнал укучыларының да теләген истә тотып, сезнең белән киңәшеп утырдым.***

**М. М.**— Хезмәтемне танучыларга, зурлаучыларга бер генә сүзем бар: рәхмәт!